# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Кадрәк торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 2

30 ноябрь 2025

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Кадрәк торак пунктында халык җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВО зонасында катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВО зонасында катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

*1. Кадрәк торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (су җыю манарасын һәм суүткәргеч челтәрләрен техник тикшерү, ремонтлау, материаллар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);*

*2. Кадрәк торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм*

*урнаштыру, урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);*

*3. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (АЦ-40 янгын сүндерү машинасына хезмәт күрсәтү (ЗИЛ-431412), запас частьләр, ягулык-майлау материаллары, хезмәт хакы).*

3. Әлеге карарны Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы

Х.Х.Нәбиуллин